ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 октябрь 2018 ел № 6285

Башкарма комитетның «Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 11 июлендәге 4140 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ санлы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 11 июлендәге 4140 нчы карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 28 июнендәге 3316 нчы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының архив фонды һәм архивлар турында» 1996 елның 13 июнендәге 644 нче Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ санлы Законы» сүзләренә алмаштырырга, «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче карары» сүзләрен «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары» сүзләренә алмаштырырга;

2) Административ регламентта:

- 1.4 пунктта:

- 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Федераль архив агентлыгының «Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль архивларында архив документларыннан файдалану тәртибен раслау турында» 2017 елның 1 сентябрендәге 143 нче приказы (алга таба – Тәртип) (хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2017 ел, 3 ноябрь, басылып чыгу номеры 0001201711020011);

- 8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ санлы Законы (алга таба – 63-ТРЗ санлы ТР Законы) («Республика Татарстан», №107, 25.07.2017);

- 11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 елның 9 августындагы 541 нче карары (алга таба – ТР МК 541 нче карары) («Татарстан Республикасы законнар җыентыгы», 16.08.2016, №13, ст. 0384)»;

- 2 бүлек «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты»н түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләрнең исеме | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга архив документларын бирү | 125-ФЗ санлы Федераль законның 24 маддәсе;<br>63 нче ТР Законының 22 маддәсе;<br>Кагыйдәләрнең 5.7, 5.12, 5.13 пунктлары |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты<br>Муниципаль хезмәтне башкаручы - Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең архив бүлеге | 125-ФЗ санлы Федераль законның 4 маддәсенең 3 бүлеге;<br>63 нче ТР Законының 7 маддәсе;<br>Архив эше турында нигезнамә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Муниципаль архивларның уку залларында (карау залларында, фонодокументларны тыңлау бүлмәләрендә, каталоглар бүлмәләрендә) яки архив хезмәткәренең контролендә архивның эш бүлмәсендә (махсус бирелгән бүлмә булмаганда) эшләү өчен файдаланучыларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка чикләүләрне исәпкә алып, Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт сере булмаган мәгълүматлардан торган башка архив документларын, аларга мөнәсәбәтле белешмә- | 125-ФЗ санлы Федераль законның 24 маддәсе, 25 маддәсе;<br>63 нче ТР Законының 22 маддәсе;<br>Кагыйдәләрнең<br>5.12, 5.13 пунктлары;<br>Тәртипнең 1.2, 3.1, 4.1.1, 4.1.3, 4.1.4, 4.1.5, 4.1.6, 4.1.7 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | эзләү чараларын һәм архивларның фәнни-мәгълүмат китапханәләрендә саклана торган басмаларны бирү | |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы | делоларга, документларга белешмә-эзләү чараларын, шулай ук уку залындагы автоматлаштырылган белешмә-эзләү чараларыннан файдалану мөмкинлеген алу – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә;<br>делоларны, документларны (файдалану чикләнгән, өлешчә сер булып саналган, чит телдәге делолардан, документлардан тыш) алу – гариза бирүче тарафыннан заказ рәсмиләштерелгән көннән башлап 2 эш көненнән дә соң түгел;<br>файдалану чикләнгән, өлешчә сер булып саналган, чит телдәге делоларны, документларны алу – гариза бирүче тарафыннан заказ рәсмиләштерелгән көннән башлап 10 эш көненнән дә соң түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы каралмаган. | Тәртипнең 3.1 - 3.6, 4.1.7 пунктлары |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, | Шәхсән (язма рәвештә) мөрәҗәгать иткәндә:<br>1. Файдаланучының яки файдаланучыны архивка җибәргән оешманың гаризасы, файдаланучының уку залында эшләү срогын озайту турында гаризасы.<br>Шәхси гаризада яки хатта файдаланучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), вазыйфасы (булган очракта), | Тәртипнең 2.1, 2.2, 2.4 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | гыйльми исеме һәм гыйльми дәрәҗәсе (булган очракта), тикшерену темасы һәм хронологик рамкалары күрсәтелә.<br>2. Шәхесене раслаучы документлар:<br>гариза бирүченең;<br>балигъ булмаган гариза бирүченең бирүченең ата-анасының яки законлы вәкиленең;<br>озата килүче затларның (шул исәптән сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле файдаланучыны озата килүче затларның законлы вәкилләренең, тәрҗемәчеләренең һәм башка ярдәмчеләренең).<br>3. Юридик затның вәкаләтләрен раслаучы документлар.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче бланкын Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкларының электрон формалары Башкарма комитетның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.<br>Гариза бирүче тарафыннан гариза кәгазь төрдә түбәндәге ысулларның берсе аша бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч язуы нигезендә, гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан);<br>почта аша. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза шулай ук, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Башкарма комитетның рәсми сайты, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелергә (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документларны тапшыру таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килешенү (муниципаль хезмәтне күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте (җирле үзидарә) органнары һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Муниципаль хезмәтне килешенү таләп ителми | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу.<br>2. Тапшырылган документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү.<br>3. Тапшырыла торган документларда алдан килешенмәгән төзәтүләр булу. | 125-ФЗ санлы Федераль законның 25 маддәсе;<br>63 нче ТР Законының 21 маддәсе;<br>Тәртипнең 2.1 пункты |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтү срогын туктату мөмкинлеге каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр:<br>1. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән яки документларны даими саклауга тапшырганда фонд барлыкка китерүче тарафыннан билгеләнгән документлардан файдалануга | 125-ФЗ санлы Федераль законның 25 маддәсе;<br>63 нче ТР Законының 21 маддәсе;<br>Тәртипнең 2.2, 3.2-3.7 пунктлары;<br>Тәртипнең 2.11.7.1, 2.11.10, 5.13 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | чикләүләр;<br>2. документларның канәгатьләнмәслек физик торышы;<br>3. балигълык яшенә җитмәгән гариза бирүченең ата-анасының берсеннән яки башка законлы вәкиленнән башка мөрәҗәгать итүе;<br>4. гариза бирүче тарафыннан Тәртипнең 4.2.5, 4.2.6, 4.2.9, 4.2.12, 4.2.19 пунктлары бозылу;<br>5. түбәндәгеләрне гамәлгә ашырганда файдалану фонды булмаган очракларда:<br>1) файдаланучылар тарафыннан соратып алынган делоларның, документларның, басмаларның төп нөсхәләрен файдаланып, архив хезмәткәрләре хезмәт йөкләмәләрен үтәгәндә – файдаланучылар тарафыннан аларга заказ бирелгән көннән башлап 120 эш көненнән артмаган срокта;<br>2) делоларның, документларның, басмаларның төп нөсхәләрен юридик һәм физик затларга – фонд барлыкка китерүчеләргә, аларның вәкилләренә яки дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының запрослары буенча вакытлыча файдалануга биргәндә – әлеге делоларны, документларны, басмаларны вакытлыча файдалануга бирү турындагы актта күрсәтелгән сроктан артмаган срокта;<br>3) делоларны, документларны, басмаларны күргәзмәгә куйганда – күргәзмә үткәрү өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | аларны архивтан бирүнең эш йөртү документы нигезендә билгеләнгән срогыннан артмаган срокта;<br>4) делоларның, документларның, басмаларның төп нөсхәләрен уку залына башка файдаланучыга биргәндә – файдаланучы тарафыннан заказ бирелгән көннән башлап 40 эш көненнән артмаган срокта. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шундый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | 125-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсенең 3 бүлеге;<br>210-ФЗ санлы Федераль законның 8 маддәсенең 1 бүлеге;<br>Тәртипнең 4.1.1 пункты |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шундый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | 210-ФЗ санлы Федераль законның 8 маддәсенең 1 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм шундый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Запрос биргәндә һәм нәтиҗәне алганда муниципаль хезмәттән файдаланучының (гариза бирүченең) кабул итүне көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Муниципаль хезмәттән файдаланучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикле инвалидларны да истә тотып. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәттән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлегенең саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләре кулланып | Муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлегенең күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләрнең булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеп алу өчен кирәкле санда бүлмәләрнең булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>инвалидларга башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачаулый торган киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль | 125-ФЗ санлы Федераль законның 24 маддәсенең 1 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла. Үзара эшчәнлек дәвамлылыгы әлеге Регламентта билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәтне күрсәтү КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыннары аша гамәлгә ашырылмый.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны Башкарма комитет сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алырга мөмкин. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза түбәндәге электрон адрес буенча электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин:<br>Башкарма комитетның рәсми сайты (http://nabchelny.ru/);<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/);<br>Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://www.gosuslugi.ru/). | 210-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 1 бүлеге |

- 3.3.4 пунктта:

- «Файдаланучыларның уку залларында эшләү кагыйгадәләре белән» сүзләрен «Россия Федерацисе дәүләт һәм муниципаль архивларында архив документларыннан файдалану тәртибе белән» сүзләренә алмаштырырга:

- 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.»;

- 5.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре буенча – күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (жирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1. маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән тапшыру яки гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән

ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.»;

- 5.1.2 һәм 5.1.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»;

5.1.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

- 5.1.4 пунктта:

- 1 пунктчаны «Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәре» сүзләреннән соң «күпфункцияле үзәк, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре,» сүзләре белән тулыландырырга;

- 3 пунктчаны «, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре» сүзләре белән тулыландырырга;

- 4 пунктчаны «, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре» сүзләре белән тулыландырырга;

- 5.1.7 пунктның 1 һәм 2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.»;

- 5.1.8. пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче һәм өченче абзацлар белән тулыландырырга:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 5.1.9 һәм 5.1.10 пунктлар белән тулыландырырга:

«5.1.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

5.1.10. Шикаятьләрне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.»;

- 5.2.1 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«5.2.1. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

- Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымтаны (белешмә) яңа редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм

аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты архив бүлеге

| Т/с | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Башкарма комитет эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең архив бүлеге башлыгы | 30-55-78 | Lyuciya.Shamsevaliv@tatar.ru |
| 2. | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе ахив бүлегенең әйдәүче белгече | 30-58-13 | Venera.Sibgatullina@tatar.ru |
| 3. | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе архив бүлегенең 1 категорияле белгече | 30-58-13 | Sazida.Zubaerova@tatar.ru |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | |
| Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе | 30-55-25 | |

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин